ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.10.2022 Олы Кайбыч ав. № 447

Өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы мәгариф оешмаларында тәрбияләнгән өчен түләүдән азат итү турында

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләрен Кайбыч муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итәргә.

2. «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә:

2.1. 1 пунктта күрсәтелгән ташламаны белем бирү оешмасында тәрбияләнүченең атасын (законлы вәкилен) хәрби комиссариатның өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакыруы турындагы белешмәсе нигезендә бирергә;

2.2. өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны кире кайтарган очракта ташламаларның гамәлдә булуын туктатуны контрольдә тоту максаты белән хәрби комиссариат белән хезмәттәшлекне алдан кайгыртырга.

3. «Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә Кайбыч муниципаль районының мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизация

кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләреннән тәрбияләнүчеләрне карауны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябреннән гражданның өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт узу вакытына кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы И.И. Хәмидуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесенең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина